**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**
**«ТУКАЙ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ НОВОТРОИЦК АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ МУНИЦИПАЛЬ БЕРӘМЛЕГЕ СОВЕТЫ»**

# КАРАР

«29» июнь 2023 ел № 32/3

**«Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы Новотроицк авыл җирлеге Советы депутаты статусы турында нигезләмәне раслау хакында» «Тукай муниципаль районы Новотроицк авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Советының 2022 елның 25 октябрендәге 25/3 номерлы карарына үзгәрешләр кертү турында**

«Татарстан Республикасы Конституциясенә үзгәрешләр кертү турында» 2022 елның 31 декабрендәге 109-ТРЗ номерлы, «Татарстан Республикасы Конституциясенә үзгәрешләр кертү турында» 2023 елның 26 январендагы 1-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы законнары, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы, «Коррупциягә каршы тору турында» 2008 елның 25 июлендәге 273-ФЗ номерлы, «Россия Федерациясендә муниципаль хезмәт турында» 2007 елның 2 мартындагы 25-ФЗ номерлы федераль законнар, Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы авыл җирлеге уставы нигезендә, муниципаль берәмлек Советы

**КАРАР БИРДЕ:**

1. «Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы Новотроицк авыл җирлеге Советы депутаты статусы турында нигезләмәне раслау хакында» «Тукай муниципаль районы Новотроицк авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Советының 2022 елның 25 октябрендәге 25/3 номерлы карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. 3 статьяның 3 пунктында «Татарстан Республикасы Президенты» сүзләрен «Татарстан Республикасы Рәисе» (алга таба – Татарстан Республикасы Рәисе) сүзләренә алыштырырга;

1.2. 18 статьяның 1 пункты «б» пунктчасында «Татарстан Республикасы Президентына» сүзләрен «Татарстан Республикасы Рәисенә» сүзләренә алыштырырга.

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы рәсми хокукый мәгълүмат порталында (http://pravo.tatarstan.ru) һәм Тукай муниципаль районының рәсми сайтында (tukay.tatarstan.ru/) урнаштырырга.

3. Әлеге карар үтәлешен контрольдә тотуны законлылык, милли мәсьәләләр һәм халык куркынычсызлыгы буенча даими комиссиягә йөкләргә.

Муниципаль берәмлек Башлыгы,
Совет Рәисе Д.М. Габделхаева